# КАРАР

**2023 ел, 12 июль** **№ 1**

**«Кукмара муниципаль районының Шепшеңәр авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 19 ноябрендәге 1 нче номерлы карарга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 11 июлендә түбәндәге мәсьәлә буенча уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районының Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Шепшеңәр авылында уздырылган гражданнар җыенының 2022 елның 19 ноябрь 1 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә, Сез ризамы?:

2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-Шепшеңәр авылында юлларны саклау, вак таш япмаларын төзү һәм ремонтлау (килешү буенча түләү, смета һәм технадзор өчен түләү);

2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

- Шепшеңәр авылында һәйкәл төзү һәм төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 89 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 45.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен гражданнар җыенының 45 катнашучысы тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен гражданнар җыенының 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: Кукмара муниципаль районының Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Шепшеңәр авылында уздырылган гражданнар җыенының 2022 елның 19 ноябрь 1 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә, Сез ризамы?:

2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-Шепшеңәр авылында юлларны саклау, вак таш япмаларын төзү һәм ремонтлау (килешү буенча түләү, смета һәм технадзор өчен түләү);

2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

- Шепшеңәр авылында һәйкәл төзү һәм төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

кабул ителгәнгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Кукмара муниципаль районы рәсми сайтында игълан итәргә һәм www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ятмас-Дусай
авыл җирлеге башлыгы Ф.Х. Гарифуллина